**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Бирючевского сельского поселения**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы Бирючевка авыл**
**жирлеге Советы**
**БАШЛЫГЫ**

**ул. Школьная, д.2, д.Бирючевка, 423307**
**Азнакаевского муниципального района**
**Тел. (8-5592) 6-18-81, факс (8-5592) 6-18-81**

**Мэктэп урамы, 2, Бирючевка авылы, 423307**
**Тел. (8-5592) 6-18-81,**
**факс (8-5592) 6-18-81**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» ноябрь 2019 ел № 88

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлегенең Бирючевка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Бирючевка авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 28 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә: Котельная урамы 1 йорттан 12йортка кадәр.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Бирючевка авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 29 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә:Мира урамы 1 йорттан12 йортка кадәр, Школьная урамы 1йорттан 4йортка кадәр,Молодежная урамы 1 йорттан 8 йортка кадэр,Центральная урамы 1 йорттан 35 йортка кадэр.

3.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Бирючевка авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты – 28 ноябрь 2019 ел 17.00 сәг.тән 18.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты – 29ноябрь 2019 ел 17.00 сәг.тән 18.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны – Бирючевка авылы, Мәктәп ур. , 2йорт, Бирючевка авыл мәдәният йорты залы;

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 24 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Бирючевка авылы, Мәктэп урамы, 2 йорт

- сайлау хокукына ия булган Бирючевка торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;

- Бирючевка торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 Бирючевка авыл җирлеге Бирючевка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- юлларга асфальт җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү) Мира ур.,Бирючевка авылы; Молодежная ур., Бирючевка авылы;

-Авыл халкына бәйрәмнәрне оештыру өчен: “Сабантуй”,”Картлар көне”,”Яна ел” бәйрәмнәре өчен;

« РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Бирючевка авылы, Школьная ур., 2 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: М.Г.Нуреева